| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ТАТАРСКО-КАНДЫЗСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАТАР КАНДЫЗЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2023 г. с. Татарский Кандыз №67

Баулы муниципаль районы Татар-Кандыз
авыл җирлеге Советының 25.05.2018 ел,
№66 карарына "Баулы муниципаль районы
Татар-Кандыз авыл җирлеге хәрби комиссариатлары
булмаган территорияләрдә беренчел хәрби
учет буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы
җирле үзидарә органнарының хәрби-учет
хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү
шартлары турында" үзгәрешләр керту
18.10.2018 ел, №85 үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Баулы муниципаль районы Татар-Кандыз авыл җирлеге Советының 25.05.2018 ел, №66 карарына "Баулы муниципаль районы Татар-Кандаз авыл җирлеге хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби учет буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының хәрби-учет хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"хәрби-исәп хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү тәртибе һәм шартлары, Россия Федерациясе Оборона министрлыгының 18.09.2019 ел, №545 боерыгы нигезендә хәрби комиссариатның «исәпкә алу һәм броньлау инспекторы» вазыйфасы буенча хезмәт өчен түләүгә ихтыяҗны исәпләүдән чыгып, әлеге максатларга федераль бюджеттан бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә билгеләнә;

2 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Бу карар рәсми басылып чыкканнан бирле көченә керә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга:

(http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Башлыгы, Рәисе М. Ш. Насыйбуллин